**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

24.10.2013 625-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2012 елның 10 сентябрендәге 351-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү, шулай ук җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар үткәрү процедурасының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2012 елның 10 сентябрендәге 351-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.12 пунктның җиденче абзацын, 6.1 пунктның 11 абзацын, 8.2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

6.1 пунктның алтынчы абзацын «соңгы хисап датасына» сүзләреннән соң «аны кабул итү турында салым органы тамгасы белән» сүзләренә алмаштырырга;

7.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, яңа абзацлар өстәргә:

«Аукционны гамәлдә булмаган дип тану турында карар Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры боерыгы белән раслана.

Яңа Аукцион үткәрү турында белдерү әлеге Нигезләмәнең 4.7 һәм 4.8 пунктларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

7.8 пунктны түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«7.8. Әгәр аукцион җиңүчесе җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукыннан язма рәвештә баш тарту турында белдерсә, Министрлык үткәрелгән аукцион нәтиҗәләрен юкка чыгару турында карар кабул итә. Шул ук вакытта аукцион җиңүчесе тарафыннан кертелгән акчаның бер өлеше кире кайтарылмый.»;

Нигезләмәне әлеге боерыкка кушымта белән тулыландырырга.

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (В.А.Тронин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Т.М. Акчуринга йөкләргә.

Министр А.Г. Сидоров

Татарстан Республикасы Экология һәм
табигать ресурслары министрлыгының
24.10.2013 №625-п боерыгы белән расланды

# Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына аукцион үткәрүнең типлаштырылган тәртибе һәм шартлары

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Үткәрелә торган аукционның максаты – кирәкле финанс, техник чараларга һәм квалификацияле белгечләргә ия булган җир асты байлыкларыннан файдаланучыны билгеләү ______________________________________________
жир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануның максаты, гомумтаралган файдалы казылма нигезендә аның атамасы
(җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме)

аукцион үткәрү тәртибе һәм шартлары (алга таба — аукцион шартлары) белән билгеләнә.

1.2. Лицензияле кишәрлектән файдалану хокукы алу өчен аукцион үткәргәндә җиңүчене ачыклау өчен төп критерий булып, аукционда катнашучыларның берсе тәкъдим иткән җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы өчен бер тапкыр бирелә торган түләүнең максималь күләме тора.

1.3. Аукционда җиңүчегә җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы биреләчәк һәм әлеге максатта лицензия биреләчәк________________________
киң таралган файдалы казылманың атамасы

________ еллык чорга.

_____________________________________________________
(җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме)

1.4. Җир асты байлыкларыннан чыгарылган гомумтаралган файдалы казылмалар җир асты байлыкларыннан файдаланучы затның милегендә тора.

1.5. Чыгару максаты —__________________________________________________
киң таралган файдалы казылма чыгару максаты һәм аның атамасы

1.6. Җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану срогы лицензияне дәүләт теркәве датасыннан чыгып исәпләнә һәм законда билгеләнгән тәртиптә озайтылырга мөмкин.

1.7. Җир асты байлыкларыннан файдаланучының хокуклары һәм бурычлары җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан килеп чыга.

## 2. Аукционда катнашучылар

2.1. Аукционда эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары, шул исәптән гади ширкәттә катнашучылар, чит ил гражданнары, юридик затлар катнаша ала, әгәр федераль законнарда башкача билгеләнмәгән булса.

2.2. Аукционда катнашучылар җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга гамәлдәге законнар таләпләренә җавап бирергә, квалификацияле белгечләргә, җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрне нәтиҗәле һәм куркынычсыз башкару өчен кирәкле финанс һәм техник чараларга ия булырга тиеш (аукцион шартларына № 3 кушымта нигезендә).

## 3. Җир асты байлыклары кишәрлеге турында гомуми белешмәләр

3.1. урнашу урыны

___________________________________
(җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме) (муниципаль район исеме)

Татарстан Республикасы муниципаль районы _____________________________________
(җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең географик бәйләнеше китерелә)

3.2. Җир асты байлыклары кишәрлегенә геологик өйрәнү һәм тау бүлеп бирү чорында, тау бүлеп бирүенең төгәл чикләрен раслаучы документларны теркәү датасыннан алып, геологик бүлеп бирү статусы бирелә.

Файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлегенең контурлары планында түбәндәге географик координаталар белән почмаклы нокталар белән чикләнгән (WGS - 84):»

| Җир асты байлыклары кишәрлегенең почмактагы нокта номеры | Төньяк киңлеге | | | Көнчыгыш озынлыгы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Градуслар | Минутлар | Секундлар | Градуслар | Минутлар | Секундлар |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Җир асты байлыклары кишәрлегенең мәйданы ______ га тәшкил итә.

3.3. Запасларны раслаганнан соң тау бүлеп бирелгән чикләре

___________________________________________
(гомумтаралган файдалы казылма атамасы)

сәнәгать категорияләрендә, техник проектны эшләү, аңа уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алу һәм кирәкле килешүләрне алу.

3.4. Җир асты байлыклары кишәрлегендә федераль, төбәк һәм җирле әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләр юк.

3.5. Түбәндәгене уздыру өчен җир асты байлыкларыннан файдаланучыга җир кишәрлеге бирү_______________________________________________________

(җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану максаты һәм гомумтаралган файдалы казылма атамасы)

җир асты байлыклары кишәрлеге чикләрендә, әлеге эшләрне үткәрү проектларын раслаганнан соң, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Җир асты байлыклары кишәрлегенең геологик характеристикасы

4.1.__________________________________________________________

4.2. ______________________________________________________________________

(минераль чималның кыскача сыйфат һәм технологик характеристикасы)

4.3. җир асты байлыклары кишәрлегендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгаруның тау-геологик шартлары __________________

4.4. ______________________________________________________________________

(запасларның категориясен күрсәтеп, җир асты кишәрлегендә киң таралган файдалы казылма запаслары (ресурслары)

5. Лицензияле кишәрлектән файдалануның төп шартлары (бүлек нигезләмәләре җир асты байлыкларыннан файдалану төрләренә һәм срокларына бәйле рәвештә үзгәрергә мөмкин)

5.1. Җир асты байлыкларыннан файдаланучының хокуклы:

а) лицензиядә билгеләнгән максатка туры килә торган эшкуарлык яки башка эшчәнлек рәвеше өчен үзенә бирелгән җир асты кишәрлегеннән файдалану;

б) гамәлдәге законнарга каршы килми торган әлеге эшчәнлек рәвешләрен мөстәкыйль сайлау;

в) үз эшчәнлеге нәтиҗәләренннән, шул исәптән чыгарылган минераль чималдан, лицензия һәм гамәлдәге законнар нигезендә файдалану;

г) үзләренең тау чыгару һәм аның белән бәйле эшкәртү производстволары калдыкларыннан, әгәр лицензиядә башкасы әйтелмәгән булса, файдалану;

д) үзенә бүлеп бирелгән тау чикләрдә файдалы казылма ятмалары мәйданнары төзүне чикләү;

е) лицензия нигезендә бүлеп бирелгән тау чикләрендә үз акчалары хисабына җир асты байлыкларын табуга өстәмә рөхсәтләрсез геологик өйрәнүләр үткәрү;

ж) лицензия бирелгән шартлардан шактый аерылып торган шартлар туганда, лицензия шартларын яңадан карау уңаеннан лицензия биргән органга мөрәҗәгать итү.

5.2. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга тиеш:

______________________ Җир асты байлыкларыннан файдалану максаты һәм аның исеме

Түбәндәге шартлар нигезендә лицензияле кишәрлектә гомумтаралган

файдалы казылмалар белән эш итү:

5.2.1. Геологик разведка һәм чыгару эшләре вакыты буенча җир асты байлыкларыннан файдаланучы түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

а) лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан алып, ____ айдан соңга калмыйча геологик йөкләмәгә туры китереп, лицензияле кишәрлектә геологик разведка эшләре проектын Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә әзерләү һәм килештерү. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләре дәүләт исәбенә алынырга һәм дәүләт реестрына «Җир асты байлыклары турында» 21.02.1992 ел, № 2395-1 Россия Федерациясе Законының 28 статьясы нигезендә кертелергә тиеш;

б) лицензияле кишәрлектә геологик эзләнү эшләрен үткәрү, __________________________ запасларын исәпләп, геологик хисап төзү һәм тапшыру

дәүләт экспертизасына юллана торган гомумтаралган файдалы казылманың исеме

______________________________

(запаслар категориясе)

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан алып билгеләнгән тәртиптә ____ айдан да соңга калмыйча;

в) геологик разведка эшләре нәтиҗәләре турында геологик хисапны Татарстан Республикасы буенча геологик мәгълүматның Территориаль фондына һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының геологик мәгълүмат фондына дәүләт экспертизасы датасыннан соң 2 айдан да соңга калмыйча тапшыру;

г) лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан алып ______ ай узганчы, лицензияле кишәрлекне эшкәртүнең техник проектын билгеләнгән тәртиптә әзерләү, килештерү һәм раслау;

д) бүлеп бирелгән тауның төгәл чикләрен билгеле торган документларны рәсмиләштерү (характерлы сызымнар, почмак нокталары координаталары белән) һәм, лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан соң ______ ай узганчы, аларны аерылгысыз состав өлеше буларак лицензиягә кертү;

е) лицензияне дәүләт теркәвенә алганнан соң _____ ай узганчы, лицензияле кишәрлектә тау әзерләү эшләрен башлау;

ж) лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан соң ____ ай узганчы проект егәрлегенә чыгу;

з) 5 февральгә кадәр Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына, Федераль экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге хезмәтенең (Ростехнадзор) Идел буе идарәсенә, «Идел буе федераль округы буенча геологик мәгълүмат территориаль фонды» Федераль бюджет учреждениесенең Татарстан филиалына, «Россия федераль геологик фонды» федераль дәүләт унитар фәнни-җитештерү предприятиесенә файдалы казылмалар запасларының торышы һәм үзгәрүе турында дөрес мәгълүматлар булган 5 нче гр формасы буенча статистик хисаплылыкны ел саен тапшыру, шулай ук тау күзәтчелеге органы белән килештерелгән файдалы казылмалар запасларын үзгәртүне нигезли торган материаллар кушымтасы белән аңлатма язулары;

и) разведкаланган, чыгарыла торган һәм җир астында калдырыла торган файдалы казылма запаслары, аларда булган компонентлар турында, файдалы казылмаларны алуга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану турында төгәл мәгълүматларны дәүләт статистикасы органнарына тапшыру.

5.22. Файдалы казылмалардан рациональ файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында җир асты байлыкларыннан файдаланучы түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

а) җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрне алып бару технологиясе һәм минераль чималны беренчел эшкәрткәндә законнар таләпләрен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган стандартларны (нормаларны, кагыйдәләрне) үтәү;

б) файдалы казылма байлыкларыннан файдалы казылмаларны тулсынча чыгару, аларны чыгарганда җир асты байлыкларының пычрануына юл куймаска, лицензияле кишәрлекне файдалы казылманың сыйфатын һәм лицензияле кишәрлекнең сәнәгый кыйммәтен киметә торган яисә аны эшләүне катлауландыра торган факторлардан сакларга;

в) маркшейдер эшләрен башкару һәм җир асты байлыкларын саклау кагыйдәләре буенча инструкция таләпләре нигезендә, маркшейдерда төшерү юлы белән җир асты байлыкларында табыла торган һәм калдырылган файдалы казылма запасларының төгәл исәбен алып барырга;

г) җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны булдырмау яисә киметү өчен кирәкле чараларны күрергә;

д) җир асты байлыкларын, атмосфера һавасын, җирләрне, урманнарны, су объектларын, шулай ук биналар һәм корылмаларны җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрнең зарарлы йогынтысыннан саклау шартларын регламентлаучы билгеләнгән тәртиптә расланган стандартларны (нормаларны, кагыйдәләрне) үтәү;

е) ятманы эшкәртүгә керткәнче, җирләрне сәнәгать җирләре категориясенә күчерү;

ж) чыгару эшен алып бару ______________________________

(киң таралган файдалы казылманың атамасы һәм бары тик ятманың тау бүлеп бирелгән чикләре чикләрендә генә;

з) җир асты байлыкларыннан файдаланучының югалтулар нормативларын еллык раслау

___________________________________________________________________

(гомумтаралган файдалы казылма атамасы), күләме буенча проект документлары составында расланган нормативлардан артмый торган;

и) җир асты байлыкларыннан файдаланучының Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы белән килештерү буенча югалтулар нормативларын үз вакытында раслау

___________________________________________________________________

(гомумтаралган файдалы казылма атамасы),

зурлыгы буенча проект документлары составында расланган нормативлардан артып киткән;

к) билгеләнгән тәртиптә килештерелгән проект документлары нигезендә ятманы эшкәртергә;

л) җир асты байлыкларыннан файдалануның барлык төрләре процессында геологик һәм маркшейдер документларын алып бару;

м) карьерда рөхсәт документларының (лицензия килешүе белән җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләр, тау эшләрен үстерү планының билгеләнгән тәртиптә килештерелгән топографик планлы топографик акт, җир кишәрлеген сәнәгать җирләре категориясенә күчерү турында карар) күчермәләре булу;

н) лицензиянең гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң,, шулай ук проект нигезендә рекультивацияләнгән законнар нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган очракта, элеккеге җир хуҗасына җирләрне кире кайтару;

о) тау эшләрен үстерү буенча техник проектлар, планнар һәм схемалар таләпләрен үтәү, нормадан тыш югалтуларны булдырмау, файдалы казылмаларның сыйфатын киметмәү һәм файдалы казылмаларны сайланма рәвештә генә эшкәртүгә юл куймау;

п) файдалы казылма ятмалары мәйданнарында үзирекле төзелешләрне кисәтү һәм әлеге мәйданнарны башка максатларда куллану тәртибен үтәү;

р) ятманы эшкәрткәндә запасларны вакытында ачарга, туфрак-үсемлекләр катламын һәм токымнарны аерым тупларга;

с) җир асты байлыкларыннан сирәк палеонтология, археология һәм башка объектлар табылганда, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына хәбәр итү;

т) җир асты байлыкларыннан файдаланганда бозылган җир кишәрлекләрен һәм башка табигать объектларын киләчәктә файдалану өчен яраклы хәлгә китерү;

у) контрольлек итүче органнарның күрсәтмәләрен үтәү.

5.23. Хезмәтне саклау һәм индустриаль куркынычсызлык максатларында җир асты байлыкларыннан файдаланучы түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

а) җәлеп ителә торган хезмәткәрләрнең һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрнең йогынтысы зонасында яшәүче халыкның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркынычсызлык;

б) куркыныч җитештерү объектларын үз вакытында проектлау, аларны декларацияләү, гамәлдәге законнарда каралган очракларда һәм тәртиптә сәнәгать куркынычсызлыгына экспертиза ясау;

в) лицензияләнә торган эшчәнлек төрләренә лицензияләр булдыру;

г) подрядчылар сыйфатында җәлеп ителә торган юридик һәм физик затларда җир асты байлыкларыннан файдалану буенча эшчәнлекне башкаруга дәүләт лицензиясе (таныклыгы, дипломы) белән расланган махсус квалификация һәм тәҗрибә булуны контрольдә тоту;

д) хәвефле җитештерү объектларын законнарда билгеләнгән очракларда дәүләт реестрында теркәү;

е) хәвефле җитештерү объектындагы авария очрагында башка затларның тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян китергән һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китергән өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә гражданлык җаваплылыгын иминиятләштерү;

ж) предприятиедә сәнәгать куркынычсызлыгы торышын, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне куркынычсыз алып бару буенча законнар, нормалар, кагыйдәләр, техник регламентлар таләпләрен үтәүгә производство контроле;

з) хәвефле җитештерү объекты персоналы өчен сәнәгый куркынычсызлык һәм хезмәтне саклау буенча күрсәтмәләр эшләү һәм раслау;

и) барлык хезмәткәрләр тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрне куркынычсыз алып бару кагыйдәләре таләпләрен үтәү;

к) тау эшләнмәләрен куркынычсыз хәлгә китерү һәм аларны консервацияләү буенча чаралар күрү, шулай ук нигезле очракларда, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору яисә туктаткан очракларда, шулай ук аның гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң аларны юкка чыгару;

л) компетенцияләренә туры китереп чаралар уздыру өчен, эшләрне башкару урыннарына вәкаләтле дәүләт күзәтчелеге органнары вәкилләренә законнар нигезендә каршылыксыз үтеп керү мөмкинлеген тудыру;

м) кыйммәтле һәм куркыныч йөкләрнең, геологик, маркшейдер һәм башка документларның, махсус корреспонденциянең, шулай ук дәүләт серенә кертелгән белешмәләрне йөртүче йөкләрнең сакланышы.

5.24. Лицензияле кишәрлек урнашкан территориянең социаль-икътисади үсешендә катнашуга җир асты байлыкларыннан файдаланучы бурычлы:

а) җир асты байлыклары участогы урнашкан территория халкының социаль-икътисадый һәм экологик мәнфәгатьләрен үтәү белән бәйле мәсьәләләрне хәл итүдә катнашырга;

б) җирле халык өчен эш урыннары оештыруны тәэмин итәргә;

в) җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан соң 30 календарь көн эчендә файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлегенең урнашу урыны буенча файдалы казылмалар чыгаруга салым түләүче сыйфатында исәпкә басарга;

г) лицензиядә билгеләнгән шартларны үтәү, җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләрне үз вакытында һәм дөрес кертү.

5.25. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына юридик һәм (яки) почта адресларын үзгәртү турында 10 көнлек срокта хәбәр итәргә.

5.3. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы уртача еллык нефть чыгаруны тәэмин итәргә тиеш

---

гомумтаралган файдалы казылма кишәрлегенең җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме ____(мең тонна). Табу күләме һәм тау эшләренең юнәлеше билгеләнгән тәртиптә эшкәртмәнең техник проектында билгеләнә.

5.4. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат аукцион шартларының 6.2, 6.3 һәм 6.4 пунктларында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләү һәм лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасын түләргә тиеш.

5.5. Җир асты байлыкларыннан файдаланганда җир асты байлыкларыннан файдаланучы әлеге аукцион шартларының 6.5-6.6 пунктларында каралган салымнарны кертә һәм түли.

5.6. Лицензияле кишәрлектән файдалану хокукы «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 20 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты нигезендә, лицензияле кишәрлектән файдалану шартларын үтәмәгән очракта, аукцион шартларының 5.2.1 пунктының «г» абзацында һәм 5.4 пунктында белдерелгән.

5.7. Лицензияле кишәрлектән файдалану хокукы, җир асты байлыкларыннан файдаланучының 5.2.1 («г» абзацыннан тыш), 5.22, 5.2.3 һәм 5.5 пунктларында бәян ителгән шартларны үтәмәгән очракта, «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 20 статьясындагы 2 өлешендә, 21 һәм 23 статьяларында билгеләнгән тәртиптә вакытыннан алда туктатылырга, туктатылырга яисә чикләнергә мөмкин.

5.8. 5.2-5.7 пунктларда күрсәтелгән төп шартлар лицензиягә һәм аның аерылгысыз состав өлешләренә кертелергә тиеш. Бу шартларны үзгәртү бары тик җир асты байлыкларыннан файдаланучының һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының ризалыгы белән генә, йә законнарда билгеләнгән очракларда гына рөхсәт ителә.

5.9. Дәгъва белдерүчеләрнең Аукционда катнашуы алар тарафыннан лицензияле кишәрлектән файдалануның чын төп шартларын тану һәм аларны лицензиягә һәм төп шартлар сыйфатында аның аерылгысыз состав өлешләренә кертүгә ризалыгын аңлата.

5.10. Җир асты байлыклары һәм аны куллану турында мәгълүмат.

5.10.1. Җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматка милек хокукы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә саклана.

5.10.2. Җир асты байлыкларыннан файдаланучының үз акчалары хисабына алынган геологик һәм башка мәгълүмат җир асты байлыкларыннан файдаланучының милке булып тора һәм билгеләнгән форма буенча геологик мәгълүматның федераль һәм тиешле территориаль фондларына, аны куллану шартларын, шул исәптән коммерция максатларында да, тапшырыла.

5.10.3. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы, әгәр дә килешүдә башкасы каралмаган булса, эшләрне башкару нәтиҗәсендә алынган геологик һәм башка җир асты байлыклары турындагы мәгълүматны фәнни һәм мөгаллимлек эшчәнлеге өчен кулланырга хокуклы.

5.10.4. Лицензиянең гамәлдә булу вакыты тәмамлангач, шул исәптән аның гамәлдә булу срогыннан алда туктатылганда, җир асты байлыкларыннан файдаланучы җир асты байлыклары участогы буенча геологик, топогеодезик һәм маркшейдер документларын саклау өчен Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына тапшыра.

Су объектлары чикләрендә булган Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар үткәрү тәртибенә һәм шартларына җир асты байлыкларыннан файдаланучының түбәндәге бурычлары кертелә:

[redacted] гомумтаралган файдалы казылмалар чыгара башлаганчы, Татарстан Республикасы Җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органына, билгеләнгән тәртиптә расланган таксклар һәм методикалар нигезендә башкарылган әлеге зыянны исәпләп чыгару кушымтасы белән, аларга су биоресурсларына китерелгән зыянны каплау турында мәгълүмат тапшырырга;

[redacted] гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару өчен лицензия хуҗасы тарафыннан кулланыла торган эчке елга һәм катнаш («елга-диңгез») йөзү судноларын ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS спутник навигациясе аппаратурасы ярдәмендә «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтыру;

## 6. Түләүләр һәм җыемнар

6.1. Аукционда катнашкан өчен җыем күләме ____________________ сум тәшкил итә һәм мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аукцион шартларына 4 нче кушымта нигезендә реквизитлар буенча Татарстан Республикасы бюджеты керемөнә күчерелә.

Аукционда катнашучыларга тотылган акчалар кире кайтарылмый.

6.2. Аукционда катнашучыларның барысы да гаризалар биргәнчегә кадәр алдан түләп кую килешүе нигезендә бер тапкыр түләүнең башлангыч күләмен түлиләр (3 нче кушымта).

6.3. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләнә торган түләүнең старт күләме (җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын алу өчен бер тапкыр түләү) __________________ сум күләмдә билгеләнә, ә Аукцион адымы – шуның

10%ы. Аукцион адымы аукцион комиссиясе карары буенча аукцион үткәрү барышында үзгәртелергә мөмкин.

Аукцион нәтиҗәләре буенча билгеләнә торган җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләү калдыгы (алдан түләү суммасын тотып калынган өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәкъдим ителгән бер тапкыр түләү суммасы) аукцион җиңүчесе тарафыннан аукционның җиңүчесе тарафыннан аукцион шартларының 4 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан алып 30 календарь көн эчендә кертелә.

6.4. Лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасы җир асты байлыкларыннан файдаланучының Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә 4 нче кушымта нигезендә реквизитлар буенча 6 000 (алты мең) сум күләмендә кертелә.

6.5. Җир асты байлыкларыннан файдаланганда җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләүләр һәм файдалы казылмалар чыгаруга салым түли, аларның ставкасы Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

6.6. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка салымнарны һәм җыемнарны түли.

## 7. Аукционда катнашу өчен гаризалар бирү һәм карау тәртибе

7.1. Аукцион үткәрелә:_____________________________________________

*(аукционны уздыру датасы һәм вакыты)*

Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы бинасында түбәндәге адрес буенча: Казан ш., Павлюхин ур., 75. Аукцион үткәрү турында мәгълүмат, сатуларны үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен, Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясенең рәсми сайтында www.torgi.gov.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының рәсми сайтында www.eco.tatarstan.ru урнаштырыла.

Белешмәләр өчен телефон: (843) 267-68-47.

7.2. Аукционда катнашу өчен мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына түбәндәгеләрне җибәрә:

1) Форма нигезендә аукционда катнашу өчен тапшырылган документларның исемлеге (1 нче кушымта);

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20.10.2012 ел, № 876 карары белән расланган форма нигезендә аукционда катнашу өчен гариза;

3) Аукцион үткәрү тәртибенә һәм шартларына 2 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүче турында белешмәләр исемлеге.

Махсус формалары билгеләнгән документлар әлеге формалар нигезендә төзелергә тиеш.

Гариза, кушымта итеп бирелә торган документлар һәм документлар исемлеге ябыштырылган конверт белән кабул ителә.

4) Ирекле формада төзелгән, теркәлә торган хат;

5) Аукционда катнашу өчен җыем кертүне раслаучы түләү йөкләмәсенең төп нөсхәсе;

6) Аукционны оештыручы хисабына бер тапкыр түләү өлеше суммасын кертүне раслаучы түләү йөкләмәсенең төп нөсхәсе.

7.3. Бер тапкыр түләнә торган түләү өлешен кертүне һәм аукционда катнашкан өчен җыем кертүне раслый торган конверт, конверт ябыштырылган күзәтүче хат 16.00 сәгатькә кадәр (Мәскәү вакыты белән).Әлеге вакыттан соң тапшырылган гаризалар карауга кабул ителми.

7.4. Аукционда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты чыкканнан соң килә торган беренче эш көнендә, аукцион комиссиясе аукционда катнашу өчен гаризаларны теркәүгә йомгак ясый.

7.5. Аукцион комиссиясе аукционның игълан ителгән шартларына туры килү-килмәүгә, шулай ук гариза бирүчеләрнең финанс, техник һәм кадрларның аукцион таләпләренә туры килүен тикшерү максатыннан аукционда катнашу өчен гаризаларга экспертиза үткәрә. Шул ук вакытта аукцион комиссиясе җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә махсус квалификациягә һәм эш тәҗрибәсенә ия булган бәйсез экспертларны (эксперт оешмаларын) җәлеп итә ала.

7.6. Гаризаларга экспертиза нәтиҗәләре буенча аукцион комиссиясе гариза кабул итү һәм гариза бирүчене аукционда катнашуга кертү яки аукционда катнашуга гариза кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Аукцион комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

7.7. Аукционда катнашуга кертү яки аукционда катнашуга кертү өчен гаризаны кире кагу турында кабул ителгән карар, аукцион комиссиясе утырышы беркетмәсе расланган көннән алып, 5 эш көне эчендә, аукционда катнашуга гариза биргән мөрәҗәгать итүчеләргә җибәрелә.

7.8. Билгеләнгән вакытка аукционда катнашу өчен җыем һәм (яки) алдан бирелә торган акчаларны түләмәгән мөрәҗәгать итүчеләр аукционда катнашуга кертелми.

7.9. «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 14 статьясы нигезендә, җир асты байлыклары участокларыннан файдалану хокукына аукционда катнашу өчен гариза кабул итүдән түбәндәге очракларда баш тартылырга мөмкин:

1) гариза билгеләнгән таләпләрне бозып тапшырылган очракта, шул исәптән аның эчтәлеге аукционның игълан ителгән шартларына туры килмәсә дә;

2) гариза бирүче аңлы рәвештә үзе турында дөрес булмаган белешмәләр тапшырганда;

3) мөрәҗәгать итүче квалификацияле белгечләр, эшләрне нәтиҗәле һәм куркынычсыз башкару өчен кирәкле финанс һәм техник чаралар, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрне башкару өчен кирәкле финанс чаралары булу-булмавы турында дәлилләрне җиткермәсә һәм җиткерә алмаса;

4) әлеге мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирелгән очракта монополиягә каршы таләпләр үтәлмәсә.

Мөрәҗәгать итүчегә аукционда катнашу өчен гариза кабул итүдән баш тарту нигезләренең әлеге исемлеге төгәл булып тора.

## 8. Аукционны үткәрү тәртибе

8.1. Аукцион аукцион комиссиясе тарафыннан үткәрелә.

8.2. Аукционда катнашырга кертелгән мөрәҗәгать итүчеләр вәкилләре аукцион уздырылган көнне, аның башланыр алдыннан, аукцион комиссиясе секретареннән теркәлү узарга һәм аңа закон нигезендә рәсмиләштерелгән, аның аукционда катнашу вәкаләтләрен раслаучы ышанычнамәсен тапшырырга тиешләр. Әгәр мөрәҗәгать итүче аның җитәкчесе тәкъдим итә икән, ул теркәгәндә аның вазыйфасына билгеләнүен (сайлануын) раслаучы документ күчермәсен тапшырырга тиеш. Аукционда катнашу өчен затларның вәкаләтләрен раслаганнан соң аларга аукционда катнашу хокукын бирә торган теркәү номерлары язылган табличкалар бирелә.

8.3. Теркәлү утыз минут эчендә башлана һәм аукцион башланганчы биш минут кала тәмамлана. Теркәлү тәмамланганнан соң, аукцион комиссиясе секретаре аукцион комиссиясе рәисенә теркәлгән катнашучыларның исемлеген, аларның теркәү номерларын һәм аукционда катнашу вәкаләтләрен раслаучы документларны тапшыра.

8.4. Аукционда катнашучыларга аукцион башлануны игълан иткәннән соң аукционга куелган җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме, аукцион үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен раслау тәртибе, бер тапкыр бирелә торган түләүнең старт күләме һәм аукцион адымы игълан ителә.

Аукцион адымының зурлыгы җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен беренче тапкыр түләү күләменең 10%ы күләмендә билгеләнә, ____________________
аның күләме ___________ сум тәшкил итә.

8.5. Аукционда катнашучы бер тапкыр бирелә торган түләүнең беренче күләмен, бер тапкыр бирелә торган түләү күләменә һәм аукцион адымы күләменә тиң булган беренче тапкыр түләү күләмен игълан итә. Әгәр беренче тапкыр түләү күләмен игълан иткәннән һәм бу әһәмияткә ия аукциончы өч тапкыр кабатлаганнан соң, аукционда катнашучыларның берсе дә үзенең теркәү номеры белән табличканы күтәрмәсә, җир асты байлыклары кишәрлеге буенча аукцион туктатыла һәм тормышка ашмаган дип танылa.

8.6. Бер табличка күтәрелгән очракта, аукционда катнашучының теркәү номерын атый, ул үз табличкасын күтәрә. Ике һәм аннан күбрәк табличка күтәрелгән очракта, аукционда катнашучының теркәү номерын атый, ул үзенең табличкасын беренче булып күтәрде. Аукцион адымнарын узу ведомствосына аукцион комиссиясе секретаре аукционда катнашучы номерын гына кертә, ул аукциончы дип атала.

8.7. Аннары аукциончы эзлекле рәвештә бер тапкыр бирелә торган түләү күләмен игълан итә. Бер тапкыр түләүнең һәр киләсе күләме аукцион адымын

арттыру юлы белән билгеләнә. Һәр бер тапкыр түләү күләмен игълан иткәннән соң, аукционда катнашучының теркәү номерын, беренче булып, үз табличкасын күтәреп, аны аукцион адымнарын узу ведомствосына кертеп, атый.

8.8. Аукцион комиссия карары буенча, 100 һәм / яки 300 һәм / яки 500 һәм / яки 700 һәм / яки 900 адым узганнан соң, аукционның адымы күләме 100 һәм / яки 500 һәм / яки 700 һәм / яки 900 адымга туры китереп, 10% күләмендә билгеләнергә мөмкин.

Кабул ителгән карар аукцион комиссиясе беркетмәсенә кертелә.

8.9. Аукцион, әгәр чираттагы тапкыр түләү күләмен игълан иткәннән соң һәм өч тапкыр аукциончы тарафыннан кабатланганнан соң, аукционда катнашучыларның берсе дә үзенең теркәү номеры язылган табличканы күтәрмәсә, тәмамлана.

8.10. Аукционның җиңүчесе дип аукционда катнашучы танылды, аның теркәү номеры, аукцион адымнарын узу ведомствосына җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен иң зур тәкъдим ителгән бер тапкыр түләү күләме кертелгән.

8.11. Аукцион нәтиҗәләре буенча аукцион комиссиясенең йомгаклау беркетмәсе төзелә, ул «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сату турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында www.torgi.gov.ru һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының рәсми сайтында www.torgi.gov.ru урнаштырыла.

8.12. Аукцион комиссиясе утырышының йомгаклау протоколы үз эченә алырга тиеш:

- аукционга чыгарыла торган җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме;
- аукцион комиссиясе әгъзалары исемлеге;
- аукционда катнашуга кертелгән гариза бирүчеләр исемлеге;
- гариза бирүчеләр исемлеге;
- җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдаланган өчен бер тапкыр түләүнең башлангыч һәм ахыргы күләме;
- аукционда катнашучыларның һәркайсының җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдаланган өчен бер тапкыр түләү күләме турында соңгы тәкъдиме;
- аукционда җиңүченең тулы рәсми атамасы.

8.13. Йомгаклау беркетмәсенә аның аерылгысыз өлеше буларак аукцион адымнарын үтү исемлеге теркәлә, ул аукциончы, аукцион комиссиясе секретаре һәм аукционда рәислек итүче тарафыннан имзалана.

8.14. Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы аукцион нәтиҗәләрен раслаганнан соң 30 көн эчендә җир асты байлыклары кишәрлегеннән аукцион җиңүчесенә файдалану хокукы бирү турында карар кабул итә, шулай ук аңа лицензия проектын һәм лицензия килешүенә кул кую өчен җибәрә.

8.15. Аукцион җиңүчесе лицензия һәм лицензия килешүе проектын алган көннән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына аларның имзаланган нөсхәләрен тапшырмаса, ул лицензиягә һәм лицензия килешүенә кул куйудан баш тарткан дип таныла һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы аукцион

нәтиҗәләрен юкка чыгару һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында карар кабул итә. Шул ук вакытта аукционда җиңүче тарафыннан алдан түләү сыйфатында кертелгән акчалар кире кайтарылмый.

8.16. Аукционда катнашучыларның барысына да, җиңүчедән тыш, алдан түләү өлешенең күләме аукцион нәтиҗәләре расланганнан соң 10 банк көне эчендә тулысынча кире кайтарыла.

8.17. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы аукционда җиңүче өчен, №4 кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә бер тапкыр (старт) түләү күләмендә түләнгән Алдан түләү өлешен аукцион шартларына ярашлы рәвештә, реквизитлар буенча күчерә.

## 9. Аукцион комиссиясенең эш тәртибе

9.1. Аукцион комиссиясе Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы боерыгы белән төзелә. Аның составын үзгәртү Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы боерыгы белән аукцион башланганчы өч көннән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә. Аукцион комиссиясе әгъзалары тарафыннан аукцион комиссиясе компетенциясенә кертелгән карарларны кабул итү буенча вәкаләтләрне аның башка әгъзаларына тапшыру рөхсәт ителми.

9.2. Аукцион комиссиясе вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- аукционда катнашу өчен гаризалар салынган конвертларны ачу;
- аукционда катнашуга гаризаларны карау, аукционда катнашуга рөхсәт бирү яки аукционда катнашу өчен гаризаларны кире кагу турында карар кабул итү;
- аукционны үткәрү; - карар кабул итү.

9.3. Аукцион комиссиясе утырышлары, әгәр аларда аның исемлек составының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы була. Аукцион комиссиясенең һәр утырышында комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган беркетмә алып барыла.

9.4. Аукцион комиссиясе карарлары, шул исәптән аукцион нәтиҗәләрен раслау турында да, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының кимендә яртысы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, комиссия утырышында рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

9.5. Карар кабул иткәндә аукцион комиссиясе әгъзасы тавыш бирүдән тыелып калырга хокуклы түгел.

9.6. Аукцион комиссиясе әгъзалары, комиссия карары белән килешмичә, үткәрелгән аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәгә аерым фикер кертә ала.

## 10. Аукционны узмаган дип тану

10.1. Аукцион үткәрелмәгән дип таныла:

- комиссия әгъзаларының килүе 5094 тән кимрәк булса;
- аукционда катнашу өчен гаризалар булмаса;
- аукционда катнашу өчен бер гариза теркәлгән булса;
- гариза бирүчеләрнең берсе дә аукционда катнашуга кертелмәгән булса;
- аукционда катнашырга бары тик бер гариза бирүче генә рөхсәт ителгән;
- аукцион комиссиясенең йомгаклау утырышында бары тик бер генә гариза бирүче катнашса яки гариза бирүчеләр катнашмаса;
- аукционда катнашучылар тарафыннан старт күләменнән зуррак дәрәҗәдә бер тапкыр бирелә торган түләү тәкъдим ителмәсә;
- аукцион үткәрү барышында әлеге Аукцион шартларын җитди бозылса.

10.2. Аукцион түбәндәгеләргә бәйле рәвештә узмаган дип танылган очракта:

- аукционда катнашу өчен бер генә гариза теркәлүе, ә мондый гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча аукцион комиссиясе тарафыннан аның игълан ителгән аукцион шартларына туры килүе турында карар кабул ителүе;
- аукционда катнашуга бары тик бер гариза бирүченең кертелүе;
- аукцион комиссиясенең йомгаклау утырышында бары тик бер генә гариза бирүченең катнашуы;
- аукционда катнашу өчен бер гариза теркәлүе, аны карау нәтиҗәләре буенча аукцион комиссиясе тарафыннан аның игълан ителгән аукцион шартларына туры килмәве турында карар кабул ителүе.

10.3. Аукционны гамәлдә булмаган дип тану турында карар Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры боерыгы белән раслана.

10.4. Аукционны үткәргәндә законнардагы таләпләрнең, суд актлары нигезендә аукцион үткәрүнең расланган тәртибен бозу очраклары ачыкланган очракта яисә җиңеп булмый торган шартлар нәтиҗәсендә, аукцион комиссиясе утырышы көненә кадәр ТР Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан аукцион уздырылуын туктату турында карар кабул ителә.

## 11.Җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия бирү

11.1. Аукционда җиңүчегә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 12.10.2009 ел, №715 карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибе нигезендә башкарыла.

11.2. Әгәр аукцион җиңүчесе җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукыннан язма рәвештә баш тарту турында белдерсә, Министрлык үткәрелгән аукцион нәтиҗәләрен юкка чыгару турында карар кабул итә. Шул ук вакытта Аукционда җиңүчесе тарафыннан алдан түләнгән акча кире кайтарылмый.

11.3. Җир асты байлыкларынан файдалануга лицензия бирүгә нигез булган беркетмә имзаланган көннән башлап ун көн узмыйча Аукцион нәтиҗәләре буенча лицензия бирү рөхсәт ителми, ә мондый беркетмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтта урнаштыру каралган булса, мондый урнаштыру көненнән соң ун көн узмыйча рөхсәт ителми.

1 1.4. Аукционның әлеге шартларында бәян ителгән, лицензияле кишәрлектән файдалануда үтәү өчен мәҗбүри булган төп шартлар лицензиягә һәм аның аерылгысыз состав өлешләренә алдан килештерелгән буларак кертелә.

## 12.Белешмәләр өчен адреслар, телефоннар

Аукционда катнашуга бәйле барлык материаллар 420049, Казан шәһәре, Павлюхин урамы, 75 йорт, 311 кабинет адресы буенча җибәрелә, тел.: (843) 267-68-47, факс: (843) 264-53-19.

Аукцион үткәрүнең
типлаштырылган тәртибенә
һәм шартларына № 1
кушымта

Аукционда катнашу өчен тапшырыла торган документларның исемлек формасы

Аукционда катнашу өчен бирелгән документлар исемлеге

Әлегесе беләнэ

_______________________________________________

(гариза бирүченең атамасы)

максатында (җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану максаты күрсәтелә) (гомумтаралган файдалы казылма атамасы күрсәтелә) Татарстан Республикасы муниципаль районында (муниципаль районның исеме) җир асты байлыклары кишәрлегеннән (җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең атамасы) файдалану хокукына аукционда катнашу өчен түбәндә санап үтелгән документлар җибәрелгәнлеген раслый.

| т/с | Документның исеме (форма №) | Битләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Вәкаләтле затның исеме, вазыйфасы һәм имзасы________________________

______________________

Кул кую датасы Мөһер

Аукцион үткәрүнең
типлаштырылган тәртибенә
һәм шартларына №2 кушымта

Гариза бирүче турында мәгълүматлар исемлеге

Түбәндәгедән файдалану хокукына аукционда катнашу өчен

______________________________________________________________

(җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме);

______________________________________________________________

(муниципаль район атамасы)

Татарстан Республикасы муниципаль районы, түбәндәге максатта

______________________________________________________________

(җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану максаты һәм гомумтаралган файдалы казылма атамасы)

гариза бирүче түбәндәге документларны тапшыра:

гариза бирүченең гамәлгә кую документларының күчермәләре (әгәр гариза бирүче булып юридик зат торса); Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан) өземтә; гариза бирүченең салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе, салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп; салым һәм җыемнар түләү буенча бурычлар булуы яки булмавы турында салым органнарыннан белешмә;

гариза бирүченең соңгы хисап датасына бухгалтерлык балансы күчермәсе, аны кабул итү турында салым органы тамгасы белән; Аукционда катнашуга гариза бирү датасына кадәр бер ай эчендә гариза бирүче счетлары буенча акчалар әйләнеше турында банк оешмаларыннан белешмәләр; кредит яки кредит килешүләре күчермәләре (булган очракта);

подряд килешүләренең күчермәләре (булган очракта); кулланыла торган технологияләр турында белешмә, аларны тасвирлап, бораулау һәм тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник чаралар исемлеге, аларның гариза бирүчегә яисә җәлеп ителә торган подрядчыга каравын дәлилләп;

гариза бирүченең яки җәлеп ителә торган подрядчыларның штат расписаниесе күчермәсе; эшләрне башкарачак белгечләрнең квалификация дипломнары күчермәләре.

Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә таныкланырга яки оригиналлар күрсәтеп тапшырылырга тиеш.

Аукцион үткәрүнең
типлаштырылган тәртибенә һәм
шартларына №3 кушымта

# АЛДАН ТҮЛӘҮ ӨЛЕШЕ ТУРЫНДА ШАРТНАМӘ № ___

Казан «____» __________2013 ел

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, алга таба «Аукционны оештыручы» дип атала,______________________________ йөзендә, ______________________________ нигезендә эш итүче, бер яктан һәм _________________________ алга таба «Мөрәҗәгать итүче» дип атала, __________________ нигезендә эш итә, __________________________ __________________________________________ икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталалар, Россия Федерациясе Граждан кодексының 380 һәм 381 статьялары һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 10.09.2012 № 351-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендәәлеге Шартнамәне төзеделәр, түбәндәгеләр турында:

## 1. ШАРТНАМӘ ПРЕДМЕТЫ

_______________________ ___________________________________

1.1. 1.1.Әлеге Шартнамә шартлары нигезендә Мөрәҗәгать итүче тарафыннан акчалар алдан түләү өлеше буларак (алга таба - алдан түләү өлеше) сум күләмендә күчерелә, бу Татарстан Республикасы муниципаль районында (җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең һәм муниципаль районның исеме) файдалану хокукына аукционда катнашу өчен старт түләвенең 10094 күләмен тәшкил итә, түбәндәге максатта

__________________________________

___________________________________________________________

(җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану максаты һәм гомумтаралган файдалы казылма атамасы)

(алга таба — Аукцион), ә Аукционны оештыручы алдан түләү өлешен Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан ачылган, бюджет оешмасына вакытлыча эш итүгә күчкән акчаларны исәпкә алуның ачылган агымдагы счетына кабул итә.

1.2. Әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән акчалар, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан, Аукцион нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүче җиңүче итеп билгеләнгән очракта, Аукцион нәтиҗәләре буенча билгеләнгән җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын биргән өчен бер тапкыр түләнә торган түләүне кертү йөкләмәләре үтәлешен тәэмин итү максатларында кертелгән алдан түләү өлеше булыптора.

## 2. АЛДАН ТҮЛӘҮ ӨЛЕШЕН КЕРТҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Алдан түләү өлеше Аукционда катнашуга гаризалар бирү срогы тәмамланганчы - сәгатькә кадәр (Мәскәү вакыты белән) _________(Аукционда катнашу өчен гаризаларны кабул итү тәмамланган дата) Аукционны оештыручы счетына кертелергә тиеш.

Алдан түләү өлеше әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән Алдан түләү өлешенең бөтен суммасы Аукционны оештыручы счетына кертелгән (түләнгән) дип санала. Алдан түләү өлешенең барлык суммасы билгеләнгән тәртиптә һәм билгеләнгән вакытта килеп җитмәгән очракта, Мөрәҗәгать итүченең Алдан түләү өлешен кертү буенча йөкләмәләре үтәлми дип санала. Бу очракта Мөрәҗәгать итүче Аукционда катнашуга кертелми.

Мөрәҗәгать итүченең Алдан түләү өлешен кертү йөкләмәсе акча Счетка күчсә һәм әлеге акчаларны Счетка күчерү турында раслый торган түләү документының күчермәсе аукцион комиссиясенә билгеләнгән чорда гариза составында тапшырылган очракта үтәлгән булып санала.

2.2. Мөрәҗәгать итүче Алдан түләү өлешен турыдан-туры үзенең хисап (агымдагы) счетыннан гына күчерә, аның номеры әлеге Шартнамәнең 6 пунктында күрсәтелә.

2.3. Мөрәҗәгать итүче Алдан түләү өлешен турыдан-туры һәм үз исеменнән, әлеге Шартнамәнең 6 пунктында күрсәтелгән реквизитлар нигезендә генә күчерә.

Мөрәҗәгать итүче исеменнән Алдан түләү өлешен өченче затлар күчергән очракта, Мөрәҗәгать итүче аукционда катнашуга кертелми.

2.4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан Шартнамә төземичә генә Алдан түләү өлеше күчерелгән очракта, Мөрәҗәгать итүче аукционда катнашуга кертелми.

2.5. Әлеге Шартнамә нигезендә күчерелгән Алдан түләү өлешенә процентлар исәпләнми.

## 3. АЛДАН ТҮЛӘҮ ӨЛЕШЕН КИРЕ КАЙТАРУ ҺӘМ ТОТЫП КАЛУ ТӘРТИБЕ

3.1. Алдан түләү өлеше әлеге Шартнамәнең 3.2-3.6 пунктларында билгеләнгән очракларда һәм чорларда кертелгән Алдан түләү өлеше күләмендә Мөрәҗәгать итүче счетына күчерү юлы белән кайтарыла.

Мөрәҗәгать итүче үзенең банк реквизитлары үзгәрүе турында Аукционны оештыручыларга кичекмәстән хәбәр итәргә тиеш. Аукционны оештыручы, әгәр мөрәҗәгать итүче Аукционны оештыручыларга үзенең банк реквизитларын үзгәртү турында үз вакытында хәбәр итмәсә, әлеге Шартнамәдә билгеләнгән Алдан түләү өлешен кире кайтару срокларын бозу өчен җавап бирми.

3.2. Әгәр Мөрәҗәгать итүче Аукционда катнашса, ләкин аны ота алмаса, Аукционны оештыручы Мөрәҗәгать итүче тарафыннан кертелгән Алдан түләү өлешен 10 (ун) банк көне эчендә кире кайтарырга тиеш.

3.3. Аукцион үткәрү датасына кадәр Мөрәҗәгать итүче тарафыннан Аукционда катнашу өчен (җитәкче, баш хисапчы һәм Мөрәҗәгать итүченең мөһере белән беркетелгән, тиешенчә рәсмиләштерелгән) гаризаны кире алган очракта, Аукционны оештыручы керткән Алдан түләү өлешен гариза алынганнан соң 10 (ун) банк көне эчендә кире кайтарырга тиеш.

3.4. Аукцион узмаган дип танылган очракта, Аукционны оештыручы аукционны игълан итү турында аукцион комиссиясе карары кабул ителгәннән соң 10 (ун) банк көне эчендә кертелгән Алдан түләү өлешен кире кайтарырга тиеш.

3.5. Аукцион гамәлдән чыгарылган очракта, Аукционны оештыручы кертелгән Алдан түләү өлеше суммасын Аукционны гамәлдән чыгару турында карар кабул ителгәннән соң 10 (ун) банк көне эчендә кире кайтарырга тиеш.

3.6. Аукционны оештыручы, аукцион комиссиясе беркетмәсенә кул куелганнан соң 10 (ун) банк көне эчендә, Аукционда катнашуга кертелмәгән Мөрәҗәгать итүчегә акчаны кире кайтарырга тиеш.

3.7. Мөрәҗәгать итүчене Аукцион җиңүчесе дип тану очрагында, Алдан түләү өлеше файдалану хокукы биргән өчен бер тапкыр кертелә торган түләүнең ахыргы күләме исәбенә исәпләнә

---

(җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең һәм муниципаль районның исеме)

Татарстан Республикасы муниципаль районы, түбәндәге максатта

---

(җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану максаты һәм гомумтаралган файдалы казылма атамасы)

аукцион нәтиҗәләре расланганнан соң 10 (ун) банк көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә.

3.8. Аукцион җиңүчесе җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензияне имзалаудан баш тартса, лицензияне дәүләт теркәвенә алган көннән соң 30 (утыз) көн эчендә үзе тәкъдим иткән бер тапкыр түләү күләме калдыгын түләмәсә, Аукционда җиңүче тарафыннан түләнгән Алдан түләү өлеше кире кайтарылмый.

## 4. ШАРТНАМӘНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУ ВАКЫТЫ

4.1. Әлеге Шартнамә яклар кул куйган мизгелдән үз көченә керә һәм яклар тарафыннан әлеге Шартнамә буенча үз йөкләмәләре тулысынча үтәлгәнчегә кадәр гамәлдә була.

## 5. АХЫРГЫ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

5.1. Әлеге Шартнамәне үтәүгә бәйле барлык мөмкин булган бәхәсләр һәм каршылыклар яклар тарафыннан сөйләшүләр алып бару юлы белән хәл ителәчәк. Бәхәсләрне һәм каршылыкларны сөйләшүләр алып бару юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, алар гамәлдәге законнар нигезендә Татарстан Республикасы Арбитраж судында карала.

5.2. Әлеге Шартнамә ике нөсхәдә төзелде, алар бер үк юридик көчкә ия.

## 6. ЯКЛАРНЫҢ АДРЕСЛАРЫ ҺӘМ БАНК РЕКВИЗИТЛАРЫ

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать ресурслары
министрлыгы
420049, Казан шәһәре, Павлюхин
ур., 75, тел.: 267-68-01, факс: 267-
68-70 ТР ФМ ТР Экология һәм
табигать ресурслары
министрлыгы

Л) 00701 ОООЗ-МинЭкиПР
«АК БАРС» БАНК ГАҖ
Казан ш., и/х с
40302810100020000798
кор/сч
30101810000000000805
БИК
049205805
инн
165903650
8 кпп
165901001

| | |
|---|---|
| ТР экология министры урынбасары | һәм Мөрәҗәгать итүче: |
| Т. М. Акчурин | ______________________________ (вазыйфа, фамилия, исем, ата исеме, имза) |
| ______________________ | |
| ________________20 ел | ________________20 ел |
| МУ | МУ |

Искәрмә:

1. Мөрәҗәгать итүченең урнашу урыны һәм банк реквизитлары турында мәгълүматлар булмаса, Шартнамә гамәлдә түгел.
2. Алдан түләү өлеше турындагы шартнамә номеры Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан бирелә.

Аукцион үткәрүнең
типлаштырылган
тәртибенә һәм
шартларына № 4
кушымта

## Аукционда катнашу өчен, лицензияләүгә бәйле гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасын, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләнә торган түләү өлешен күчерү өчен реквизитлар

ТР буенча ФКИ (ТР Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы) ИНН 1659036508 КПП 165901001
р/с 40101810800000010001

ТР Үзәк Банкының Казан шәһәрендәге бүлеге
БИК 049205001
ОКТМО ятманы эшкәртү урыны буенча күрсәтелә

<u>Бюджет классификациясе коды һәм түләүнең билгеләнеше:</u>

| | |
|---|---|
| 1 КБК 701 1 12 02102 02 0001 . 120 | - «Башка түләүләр» (аукционда катнашу өчен җыем) |
| 2 КБК 701 12 02012 0000 . 120 | - «Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләү» (бер тапкыр түләү калдыгы) |
| КБК 701 1 08 07082 01 1000 . 110 | - «Дәүләт пошлинасы» (лицензия биргән өчен җыем) |

## Вакытлыча файдалану өчен һәм кире кайтарылырга тиешле акча күчерү реквизитлары (бер түләнә торган түләүнең алдан түләнә торган өлешен кертү өчен)

ТР Финанс министрлыгы, ТР Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы
ЛР 00701 ОООЗ-МинЭиПР РТ
«АК БАРС» БАНК ААҖ Казан шәһәре
р/с 40302810100020000798
кор/сч 30101810000000000805

БИК 049205805
инн 1659036508 кпп 165901001